ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 16.10.2024

**К А Р А Р** № 954

**2025 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 февралендәге 273 номерлы Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге 448 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2025 елга кушымтада китерелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны;

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 нче пунктында расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Хәкимуллин

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2024
елның 16 октябре 954нче
номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 119559 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 181658 |